СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЮГАРЫ ОСЛАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

21.09.2015 с. Верхний Услон № 1-12

## Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында

Югары Ослан муниципаль районы Советының вәкаләтләр чоры тәмамлану сәбәпле, 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 37 маддәсе, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 26 нчы маддәсе, Югары Ослан муниципаль районының Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Югары Ослан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итәргә.
2. Конкурска документлар кабул итү 2015 елның 22 сентябреннән 2015 елның 12 октябренә кадәр муниципаль район Советы бинасында түбәндәге адрес буенча: Ю.Ослан ав., Чехов ур., 18 йорт, Югары Ослан муниципаль районы Советының оештыру бүлеге начальнигы кабинеты 8 дән 17 сәгатькә кадәр, шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, 2-22-25 телефон.
3. Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссиясе составын 6 кеше күләмендә расларга, 1 нче кушымта нигезендә.
4. Конкурс комиссиясе 2015 елның 13 октябреннән 15 октябренә кадәр Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатларны конкурс нигезендә сайлап алуны уздырырга һәм 2015 елның 16 октябреннән дә соңга калмыйча Югары Ослан муниципаль районы советына кандидатлар турында мәгълүмат бирергә тиеш.
5. Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт проектын 2 нче кушымта нигезендә расларга.
6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Югары Ослан муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгару

-

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге  башлыгы урынбасары В.Ю. Раковка йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан  муниципаль районы
Югары Ослан авыл җирлеге  Башлыгы М. Г. Зиятдинов

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге Советының 2015 елның 21 сентябрендәге № 1-12 карарына
1 нче номерлы кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына кандидатураны карау өчен конкурс комиссиясе
СОСТАВЫ

Конкурс комиссиясе рәисе

1. Осянин Сергей Викторович - Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге Башлыгы урынбасары;

Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары

2. Раков Вячеслав Юрьевич - Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге Башлыгы урынбасары;

Конкурс комиссиясе секретаре

3. Камалетдинова Гөлия Фидаиловна - Югары Ослан муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгы.

Конкурс комиссиясе әгъзалары

4. Тихонова Хатирә Зариповна - Югары Ослан районы Башлыгының коррупциягә каршы көрәш буенча ярдәмчесе;
5. Зарипова Дана Искәндәр кызы - 1 нче сайлау округы буенча Югары Ослан авыл җирлеге Советы депутаты;
6. Мансуров Ришат Мансурович -6 нчы сайлау округы буенча Югары Ослан авыл җирлеге Советы депутаты.